ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Шеланга

20.11.2018 № 163

Югары Ослан муниципаль районы Шиланга авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы нигезендә, "2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 2018 елның 19 ноябрендәге 297 номерлы җирле референдумда кабул ителгән ТР Югары Ослан муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе карарын тормышка ашыру максатларында,

Шеланга авыл җирлеге башкарма комитеты
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Н. В. Антонова

Шеланга авыл җирлеге
башкарма комитетының

2018 елның 20
апреленнән № 163
карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Шиланга авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Шеланга авылында Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчасын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.04.2019 елга кадәр Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

в) 1 төркем инвалидлар

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) күпбалалы гаиләләр,

б) уку йортлары студентлары,

түләүләр күләме җирле референдум карарында билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар ТР Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнарның түләүләре физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша, Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/.сылтама буенча башкарыла.

7. Түләү фактын раслау - приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.